**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«11» ноябр 2019 ел №57/2

«Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 20 сентябрдагы «Җир салымы турында» 30/2 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләрен үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ санлы Федерал законның 2 маддәсе 75 пункты, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципал берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 2 сентябрдагы «Җир салымы турында» 30/2 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрн кертергә:

1.1. «Җир салымы турында» карарның 2 өлешендә өченче һәм бишенч абзацларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,3% (торак фондына һәм торак коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына кермәгән объектка туры килә торган яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш);»;

«5) торак фонд биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,2% (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларын кермәгән объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш).».

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнвареннән үз көченә керә, ләкин мәгълүмат стендларында һәм районның рәсми сайтында урнаштырылган көннән соң бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Мәләкәс авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.И.Артемьев